СОВЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**31 октябрь 2022 ел** **№1**

**Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Казанбаш авылында граждannарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Үрнәк авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Казанбаш авылында Казанбаш авылы, Киров урамы, 49 нчы йорты адресы буенча урнашкан Казанбаш мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2022 елның 21 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Казанбаш авылында Казанбаш авылы, Киров урамы, 49 нчы йорты адресы буенча урнашкан Казанбаш мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2022 елның 21 ноябренә 11 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Казанбаш авылында Казанбаш авылы, Киров урамы, 49 нчы йорты адресы буенча урнашкан Казанбаш мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2022 елның 21 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.:

1 нче этап: Киров, Җиңү, М.Хәстиев урамнарында яшәүчеләр;
2 нче этап: Мәктәп, Яшьләр, Тынычлык урамнарында яшәүчеләр;

3 нче этап: Г.Тукай, Татарстан, Азин урамнарында яшәүчеләр.

5. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Казанбаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

1. Җирле әһәмияттәге юлларның буйга профилен төзәтү;

2. Киров урамындагы күпердән 62 нче йортка кадәр юл-урам челтәренә вак грунтташтан нигез салу;

3.Тынычлык урамындагы күпергә ремонт ясау;

4. Торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

6.Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Казанбаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Үрнәк авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

7.Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм халык күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Казанбаш авылы, Киров урамы, 49 йорт.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы В.Р.Габделхаков

СОВЕТ УРНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН1609012639